# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Сөякәй торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

18 нче ноябрь, 2023 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 елның 17 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Сөякәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге автомобиль юлларын җайлау, төзекләндерү һәм тоту буенча юл эшчәнлегенә:

- Тукай һәм Бакча урамнарын җәйге грейдерлау шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;
- Тукай һәм Бакча урамнарын кышкы хезмәт күрсәтү шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;
- Юл буйларындагы үләннәрне чабу;
- Тукай урамын гравийлы юлларның профилен торгызу максатыннан,гравий салып тигезләү.

2. Урам яктырткычларын көйләү:

- Сөякәй торак пунктында техник хезмәт күрсәтү шартнамәсе буенча хезмәтләргә түләү;
- Диодлы лампалар сатып алу;
- Сөякәй торак пунктында урам уты челтәрләрен ремонтлау.

3. Халыкка су бирү,чистарту, транспортлау, су чыганакларыннан суны алу инженер җайланмаларын, су күтәрү башнясын һәм су бирү системаларын ремонтлау:

- Сөякәй һәм Бәкәбез торак пунктын су белән тәэмин итү буенча су күтәрү башнясын һәм су алу системаларын ремонтлау һәм карап тору;
- Сөякәй һәм Бәкәбез торак пунктларына су куучы башняның сакланулы зонасын чистарту, үләнен чабу;
- Сөякәй һәм Бәкәбез торак пунктларына су куу башнясының су сыйфатына лаборатор тикшерүләр уздыру.

4.Җир асты суларының( чишмәләр) чыгу урыннарын төзекләндерү.

- Сөякәй авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү;
- Сөякәй авылындагы чишмә территориясе чабу.

5. Беренчел янгын куркынычсызлыгы эшчәнлеген тәэмин итү:

- Урамнар өчен янгынга каршы сигнал күрсәткечләре алу;
- Янгынга каршы гидрантларга ремонт үткәрү, аларның территорияләрен төзекләндерү.

6.Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалау,төзекләндерү эшләре:

- Зиратлардан каты көнкүреш калдыкларын чыгару;
- Сөякәй авылы зиаратында коймаларны ремонтлау һәм койма тоту;
- Кыргый куак һәм агачларны кисү;
- Зиратны чабу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 55 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 40. Бу 73% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 37 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 3 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең Сөякәй торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Сөякәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

4. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге автомобиль юлларын җайлау, төзекләндерү һәм тоту буенча юл эшчәнлегенә:

- Тукай һәм Бакчаурамнарын җәйге грейдерлау шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;
- Тукай һәм Бакча урамнарын кышкы хезмәт күрсәтү шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;
- Юл буйларындагы үләннәрне чабу;
- Тукай урамын гравийлы юлларның профилен торгызу максатыннан,гравий салып тигезләү.

2. Урам яктырткычларын көйләү:

- Сөякәй торак пунктында техник хезмәт күрсәтү шартнамәсе буенча хезмәтләргә түләү;

- Диодлы лампалар сатып алу;
- Сөякәй торак пунктында урам уты челтәрләрен ремонтлау.

3. Халыкка су бирү,чистарту, транспортлау, су чыганакларыннан суны алу инженер җайланмаларын, су күтәрү башнясын һәм су бирү системаларын ремонтлау:

- Сөякәй һәм Бәкәбез торак пунктын су белән тәэмин итү буенча су күтәрү башнясын һәм су алу системаларын ремонтлау һәм карап тору;
- Сөякәй һәм Бәкәбез торак пунктларына су куучы башняның сакланулы зонасын чистарту, үләнен чабу;
- Сөякәй һәм Бәкәбез торак пунктларына су куу башнясының су сыйфатына лаборатор тикшерүләр уздыру.

4.Җир асты суларының( чишмәләр) чыгу урыннарын төзекләндерү.

- Сөякәй авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү;
- Сөякәй авылындагы чишмә территориясе чабу.

5. Беренчел янгын куркынычсызлыгы эшчәнлеген тәэмин итү:

- Урамнар өчен янгынга каршы сигнал күрсәткечләре алу;
- Янгынга каршы гидрантларга ремонт үткәрү, аларның территорияләрен төзекләндерү.

6.Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалау,төзекләндерү эшләре:

- Зиратлардан каты көнкүреш калдыкларын чыгару;
- Сөякәй авылы зиаратында коймаларны ремонтлау һәм койма тоту;
- Кыргый куак һәм агачларны кисү;
- Зиратны чабу.

5. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче
Октябрь авыл җирлеге башлыгы И.М.Ханнанов